**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы**
**Олы Шәмәк авыл җирлегенең Кече Шәмәк торак пунктында**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**21 ноябрь 2019 ел** **№ 2**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Олы Шәмәк авыл җирлегенең Кече Шәмәк торак пунктында гражданнар җыены **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районыны Олы Шәмәк авыл җирлегенең Кече Шәмәк пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына хезмәткә чакырылган гражданнар, иректән мәхрүм итү урыннарындагы гражданнардан тыш, 2020 елда 700 сум күләмендә үзара салым кертүне гамәлгә ашырырга.

2. Аннан алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен, түбәндәге эшләрне башкару өчен юнәлдерергә:

- Кече Шәмәк авылындагы Партизан ур., Совет ур., Җиңүнең 40 еллыгы урамнарын төзекләндерү;
- Кече Шәмәк авылы зираты территориясен койма белән әйләндереп алу.

**Халык җыенында**
**рәислек итүче** **А.И. Афанасьев**

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Олы Шәмәк авыл җирлеге башлыгы** **А.И. Афанасьев**